ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $6^3$ статья өстәргә:

“$6^3$ статья. **Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрелә торган муниципаль берәмлекләр**

1. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә, шулай ук әлеге Законга кушымтада каралган исемлеккә кертелгән башка шәһәр округларында һәм муниципаль районнарда мәҗбүри булып тора.

2. Башка муниципаль берәмлекләрдә эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар

проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау җирле үзидарә органнары тарафыннан үз инициативалары белән башкарылырга мөмкин.

3. Муниципаль районнарны һәм шәһәр округларын әлеге статьяның 1 өлешендә каралган исемлеккә кертү өчен түбәндәге критерийлар булырга тиеш:

1) муниципаль район, шәһәр округы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны муниципаль район, шәһәр округы даими халкының ун мең кешесенә кимендә 250 берәмлек тәшкил итү;

2) муниципаль районның, шәһәр округының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы законы белән аерым дәүләт вәкаләтләре бирелү.

4. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының әлеге статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында каралган критерийга туры килүе Татарстан Республикасы норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрергә һәм норматив хокукый актларына экспертиза ясарга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан ел саен статистика мәгълүматларына нигезләнеп билгеләнә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган исемлеккә әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән критерийларның икесенә дә туры килгән муниципаль районнар һәм шәһәр округлары кертелә.

6. Муниципаль районнарны һәм шәһәр округларын әлеге статьяның 1 өлешендә каралган исемлектән төшереп калдыру өчен аларның әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәве нигез була.”;

2) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына кушымта

**Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге**

1) Әлмәт муниципаль районы;
2) Апас муниципаль районы;
3) Балтач муниципаль районы;
4) Бөгелмә муниципаль районы;
5) Буа муниципаль районы;

6) Югары Ослан муниципаль районы;
7) Биектау муниципаль районы;
8) Алабуга муниципаль районы;
9) Зәй муниципаль районы;
10) Зеленодольск муниципаль районы;
11) Кукмара муниципаль районы;
12) Лаеш муниципаль районы;
13) Минзәлә муниципаль районы;
14) Түбән Кама муниципаль районы;
15) Яңа Чишмә муниципаль районы;
16) Питрәч муниципаль районы;
17) Саба муниципаль районы;
18) Тукай муниципаль районы;
19) Теләче муниципаль районы;
20) Чистай муниципаль районы;
21) Чаллы шәһәре.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2016 елның 11 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 6 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 26 декабрь
№ 106-ТРЗ